ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2021 ел № 318

2021 елның IV кварталына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, "Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" коммерцияле булмаган партнерлыкның үткәрелгән эксперт-консультация советы ("Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" коммерцияле булмаган партнерлыгының 2021 елның 25 гыйнварындагы 10 номерлы "Бәяләр диапазонын билгеләү турында" хаты) Әгерҗе шәһәрендә һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында торак урыннарның бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясенең нормативын 2021 елның IV кварталына 36 735 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе А.Э. Акбашев